**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21.05.2018** **№ 1103**

**«Биектау муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын Биектау муниципаль районы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентын» раслау турында**

“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законны, “Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзелеше белән бәйләнгән торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын Биектау муниципаль районы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: //pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районы рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы

Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Д.И. Зәйнетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
«Расланды»
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 21 маендагы 1103 номерлы карары белән

**Биектау муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент Биектау муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру дәүләт функциясен башкару буенча (алга таба – дәүләт функциясе) административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели, шулай ук дәүләт функциясен үтәгәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм предприятиеләре, юридик затлар һәм физик затлар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт функциясен үтәү Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тормышка ашырыла (алга таба – Башкарма комитет).

1.3. Дәүләт функциясен үтәү максатлары белән бәйле рәвештә, ведомствоара мәгълүмати үзара мөнәсәбәтләрне кулланып, шул исәптән ведомствоара сорату ярдәмендә, түбәндәгеләр тарафыннан эшкәртелә торган документлар һәм материаллар кулланыла:

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашуы һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 1 өл.);

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашуы һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл, 2.2 пункты);

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күп фатирлы йортлар төзелеше белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”

2007 ел, 27 декабрь, 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8, 9 статьялары);

Татарстан Республикасы Арбитраж суды (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл. 11 пункты, 14өл.,15өл.,16өл.);

Биектау район прокуратурасы (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл., 11.1, 12 пунктлары);

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл, 2.1 пункты);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашуы һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл., 2.2 пункты);

Монополиягә каршы Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең суд приставларының Биектау район бүлеге (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 32.2 ст. 5 өлеше);

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәте (“Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 6 өл., 2.1 пункты);

массакүләм мәгълүмат чаралары;

башка оешмалар.

1.4. Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП);

Россия Федерациясе Торак кодексы;

“Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон);

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”, 2006 ел, 2 май, 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»,

2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон);

"Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисап тотуы турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 ел, 27 октябрь, 645 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклыгын бәяләү нормативлары турында" 2006 ел, 21 апрель, 233 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында", 2010 ел, 30 июнь, 489 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 19 апрель, 724-р номерлы боерыгы белән расланган "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеге";

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 ел, 30 апрель, 141 номерлы боерыгы;

Финанс базарлары буенча федераль хезмәтнең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын исәпләү тәртибе турында күрсәтмә раслау турында» 2006 ел, 30 ноябрь, 06-137/пз-н номерлы боерыгы;

Финанс базарлары буенча федераль хезмәтнең «Төзүчеләрнең өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен кертелә торган хисаплылыгы рәвешләрен тутыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2006 ел, 12 гыйнвар, 06-2/пз-н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Проект декларациясе формасын раслау турында", 2016 ел, 20 декабрь, 996/пр номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектына карата төзүченең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне раслау турында" 2016 ел, 09 декабрь, 914/пр боерыгы;

"Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында", 2003 ел. 12 май, 16-ТРЗ номерлы Татарсан Республикасы Законы;

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында", 2004 ел, 28 июль, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

"Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка

объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 ел, 27 декабрь, 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 ел, 11 октябрь, 750 номерлы карары;

Татарстан Республикасы “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставы;

башка закон актлары белән.

1.5. Дәүләт функциясенең предметы булып тора:

214-ФЗ номерлы Федераль законның нигезләмәләрен үтәүне контрольдә тоту;

өлешле төзелештә катнашучыларның законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклау;

күп фатирлы йортлар төзү өчен торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан гражданнарның акчаларын җәлеп итү өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләрен үтәүне контрольдә тоту;

гражданнар һәм юридик затлар мөрәҗәгатьләрендә куелган мәсьәләләрне хәл итү, гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен материалларны әзерләү буенча чаралар күрү;

өлешле төзүдә катнашу турында законнар өлкәсендә хокук бозуларны булдырмау һәм кисәтү.

1.6. Дәүләт функциясе башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан түбәндәге формада тормышка ашырыла:

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның нигезләмәләрен үтәүне контрольдә тоту;

- өлешле төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнелә торган акча чараларын төзүчеләр тарафыннан максатчан куллануны тикшерү;

- квартал саен күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруы турында хисапны тикшерү;

- төзүченең проект декларациясен урнаштыру тәртибен һәм кагыйдәләрен тикшерү;

- Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясының 3 өлешендәге һәм 123.1 статьясындагы, алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш, таләпләрне үтәүне тикшерү;

- төзүчеләр тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы белән билгеләнгән мәгълүматны ачу һәм урнаштыруны тикшерү;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән, төзүченең һәм проект декларациясенең туры килүе турында бәяләмә бирү яки әлеге бәяләмәне бирүдән дәлилләнгән баш тарту.

1.7. Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затлары дәүләт функциясен башкарган вакытта хокуклы:

- 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә

катнашучылар тарафыннан килешү буенча түләнелә торган акча чараларын төзүчеләр тарафыннан максатчан куллануны тикшерергә;

- рәсми статистик мәгълүматны формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле төзүчеләр эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

- башкарма хакимиятнең федераль органыннан һәм аның территориаль органнарыннан, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрындагы (алга таба - хокукларны теркәү органы) белешмәләрне, күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә төзүчеләрнең эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

- төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән чорда, исемлеге Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан төзелә торган, төзүчеләрнең күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне һәм (яисә) документларны алу;

- җирле үзидарә органнарыннан күп фатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны (шул исәптән күпфатирлы йорт һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзүгә бәйле документларны) алырга;

- квартал саен төзүчедән, торак-төзелеш кооперативыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруы турында, шул исәптән төзүченең төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графиклары үтәве турында хисаплылык, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән, аралык һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылылыгын алырга;

- төзүчеләрнең күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекләрен контрольдә тотарга;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның таләпләрен үтәүне, шул исәптән, 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре буенча, Россия Федерациясе Үзәк банкыннан, төзүче белән җаваплылыкны үз өстенә алу килешүе төзелгән банкның туры килүен, яки төзүче белән иминият шартнамәсе төзегән иминият оешмасы турында мәгълүматны контрольдә тотарга;

- күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүче затларга, шулай ук

күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итү мәсьәләләре буенча башка Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, вәкиллекле орган норматив хокукый актлары белән белән билгеләнгән таләпләр җибәрергә һәм әлеге кагыйдә бозуларны бетерүнең срокларын билгеләргә;

- күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүче затлар өчен 214-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча кирәкле чараларны күрергә;

- өлешле төзүдә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә;

- 214-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Торак кодексы белән каралган башка вәкаләтләрне томышка ашырырга;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган нигезләрдә төзүченең күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген билгеле бер чорга туктату турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү;

- 214-ФЗ Федераль закон таләпләрен берничә тапкыр яисә җитди бозган очракта, шулай ук федераль законнарда каралган бүтән очракларда төзелеш өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүче затны ликвидацияләү турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү;

- төзүче тарафыннан түбәндәгеләрне үтәүне контрольдә тотуны тормышка ашырырга:

а) төзүчегә карата 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясы, 2 бүлеге белән билгеләнгән таләпләрне;

б) алар тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга карата 214-ФЗ Федераль законның 3.1 статьясы белән билгеләнгән таләпләрне;

в) төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графикларын;

г) өлешле төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнелә торган акчаларның исәбен алып баруга 214-ФЗ Федераль законның 18 статьясы 1.2 өл. белән билгеләнгән таләпләрне;

- төзүчедән физик зат турында ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат – төзүче ия булган (капиталында 25 проценттан артык катнашу булган) мәгълүматны алырга;

- төзүчедән инженер тикшерүе, архитектура-төзелеш проектлавы һәм төзелеше эшләрен уздыру буенча товарлар китерү һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүче затлар турында, юридик затның тулы исемен, адресын (урнашкан урынын), шулай ук андый товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең һәм әлеге затта күрсәтелгән эшләр төрәре, товарлар китерү һәм хезмәтләр күрсәтүне тормышка ашыруга тиешле хокук (рөхсәт кәгазе) булуы турында мәгълүматны күрсәтеп, әгәр дә Россия Федерациясе законнары белән күрсәтелгән хокукларның (рөхсәт кагазләренең) булуы турында таләп булса, вәкиллекле башкарма хакимият федераль органы билгеләгән тәртиптә һәм срокларда мәгълүмат алу;

- Биектау муниципаль районы рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) төзүченең эшчәнлеген тикшерү уздыру турында мәгълүматны урнаштырырга, Россия Федерациясе законнары белән алырга мөмкин булмаган мәгълүматлардан кала, шулай ук контроль органының төзүчене, аның вазыйфаи затларын 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карарлары турында мәгълүматлар җибәрергә;

- хокук бозулар буенча җинаять эшләрен кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә;

- күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны теркәүне тормышка ашыручы дәүләт органына, төзүчедә күп фатирлы йортлар төзү (булдыру) өлешле төзүдә катнашучы граждан-катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукы булмавы турында, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, 2.3 бүлегендә күрсәтелгән карарларны да беркетеп җибәрү;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законны бозу белән бәйле гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләрен карау;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 19 апрель, 724-р номерлы карары белән расланган документлар исемлегенә кертелгән, башка дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хакимияте органнары яки җирле үзидарә органнарына ведомство карамагында күрсәтелгән документлар булган оешмалардан документлар һәм (яки) мәгълүмат алырга. Юридик заттан алда күрсәтелгән документларны таләп итү тыела;

- җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга.

1.8. Башкарма хакимиятнең вәкиллекле вазыйфаи затлары дәүләт функциясен тормышка ашырган ваккытта, күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелеш, торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күп фатирлы йортлар төзелешендә гражданнарның акчасын җәлеп итүне контроле өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген тормышка ашыруны регламентлаучы норматив хокукый документларның таләпләрен үтәргә тиешле.

1.9. Административ регламентны үтәү максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

юридик зат – төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне тормышка ашыручы юридик зат, юридик затны оештырудан башка шәхси эшмәкәр;

төзүче – оешу-хокук рәвешләренә бәйсез рәвештәге, мөлкәтендә, аренда, субаренда хокукында яисә «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 ел, 24 июль, 161-ФЗ номерлы Федераль законда, РФ Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукында җир кишәрлегенә ия булган һәм шушы җир кишәрлегендә төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә күпфатирлы йортлар һәм (яисә), җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен 214-

ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче юридик затлар;

(Төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта:

төзүче – хуҗалык җәмгыяте:

шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә, йортларны төзүче сыйфатында, һәм (яисә) техник заказчы һәм (яисә) генераль подрядчы сыйфатында төзелеш подряды килешүе нигезендә эксплуатациягә кертүгә алынган рөхсәтләр нигезендә җыеп исәпләгәндә аның яисә аның төп җәмгыятенең яисә төп җәмгыятьнең хуҗалык итүче теләсә нинди җәмгыятенең, гомуми мәйданы кимендә биш мең квадрат метрдан да ким булмаган шундый күпфатирлы йортларны төзүдә (булдыруда) (кимендә өч еллык) катнашу тәҗрибәсенә ия булган;

мөлкәтендә, аренда, субаренда хокукында яисә “Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында” 2008 ел, 24 июль, 161-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – “Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында” Федераль закон), РФ Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукында җир кишәрлегенә ия булган һәм шушы җир кишәрлегендә төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә күпфатирлы йортлар һәм (яисә), җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүче;

аталышында «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре кулланылган.

Төзүче дигәндә “Россия Федерациясе башкаласы статусы турында”, 1993 ел, 15 апрель, 4802-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә оештырылган коммерцияле булмаган оешма).

Өлешле төзү объекты – күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектын эксплуатациягә керткәннән соң, өлешле төзү катнашучысына тапшырылырга тиешле һәм күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты составына керүче, өлешле төзү катнашучысы акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган торак яки торак булмаган бина, машина кую урыны.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, тикшерү уздырган вакытта хокуклы:

1) тикшерү уздырган вакытта турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) башкарма комитеттан, аның вазыйфаи затларыннан, тикшерү предметына һәм аны тәкъдим итү «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган мәгълүматны алырга;

2.1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында башкарма комитет тарафыннан, башка дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт хакимияте органнары яки җирле үзидарә органнары ведомство карамагында булган оешмалардан алынган, аларда булган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышырга;

2.2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Башкарма комитетка үз ихтыяры белән тапшырырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук Башкарма комитет вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

4) тикшерү уздырылганда башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

5) Россия Федерациясе Президенты карамагында шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне, яисә Татарстан Республикасында шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Биектау муниципаль районы территориясендә күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеген тормышка ашырган вакытта юридик зат тиешле:

күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелеш өлкәсендә контроль һәм күзәтчелекне тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны һәм (яки) документларны тәкъдим итәргә;

квартал саен башкарма комитетка күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисапны, шул исәптән шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү буенча да тәкъдим итәргә;

Башкарма комитетның вәкиллекле вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән күрсәтмәләрдә күрсәтелгән кагыйдә бозуларны бетерергә;

Татарстан Республикасы Министрлыклары һәм ведомстволары вәкиллекле вазыйфаи затлары белән кертелгән административ җаваплылыкка тарту буенча карарларны үтәргә.

1.11. Дәүләт функциясен тормышка ашыру нәтиҗәсе булып, юридик затлар тарафыннан, юридик затлар тарафыннан, күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен өлешле төзелеш өлкәсендә закон таләпләрен тоту, һәм, кагыйдә бозулар ачыкланган очракта, аларны кисәтү һәм (яки) андый кагыйдә бозуларның нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән чаралар кабул итү, шул исәптән аларны җибәргән затларны җаваплылыкка тарту тора.

Башкарма комитет тарафыннан дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

Юридик затны тикшерү актын төзү (административ регламентка 4 нче кушымта) (тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланды);

ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрү (административ регламентка 8 нче кушымта);

төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү.

## II. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә карата таләпләр

2.1. Дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында мәгълүмат Башкарма комитетның вәкиллекле вазыйфаи затлары тарафыннан тормышка ашырыла:

турыдан-туры шәхси кабул итү вакытында;

язмача рәвештә (әлеге Административ регламентның 2.2 пукнтында күрсәтелгән, почта буенча мөрәҗәгать иткәндә реквизитлар буенча);

дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары мәгълүмат такталарында мәгълүмат урнаштыру.

Әлеге Административ регламент, дәүләт функциясен тормышка ашыру тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Биектау муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) урнаштырылалар һәм яңартылалар (әлеге Административ регламентка үзгәрешләр керткән саен).

2.2. Башкарма комитетның урнашкан урыны:

- 422700, ТР, Биектау районы, Биектау т/ю ст. бистәсе, Кооператив ур., 5 й.

2.3. Белешмәләр өчен Башкарма комитет телефоннары: 8 (84365) 2-30-68.

Башкарма комитетның электрон почта адресы: Hamitov.Lenar@tatar.ru

2.4. Башкарма комитетның эш графигы:

- 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәг. 13.00 сәг. кадәр.

Бүлектә гариза бирүчеләрне, аларның вәкилләрен кабул итү графигы – сишәмбе, 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кабул итү көннәре һәм сәгатьләре:

- атна саен, сишәмбе көнне, 14.00 сәгатьтә Башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) урынбасары тарафыннан;

2.5. Күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен өлешле төзелеш өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча дәүләт функцияләрен тормышка ашыру түләүсез нигездә башкарыла. Дәүләт функцияләрен үтәү, яисә дәүләт функцияләрен үтәү кысаларында аерым административ процедуралар үтәү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү каралмаган.

2.6. Дәүләт функциясен үтәү срогы тәшкил итә:

Россия Федерациясе законнары һәм "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1.1 өлеше нигезендә теркәлгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына: Хуҗалык җәмгыятьләре, хуҗалык партнерлыклары, җитештерү кооперативлары, кулланучылар кооперативлары һәм индивидуаль эшкуарларга (алга таба - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары) карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы (алга таба - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары) - планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы арта алмый:

кече предприятие өчен (алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны 100 кешегә кадәр тәшкил итә) - елына 50 сәгатьтән;

- микропредприятиеләр өчен (алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны 15 кешегә кадәр тәшкил итә) - елына 15 сәгатьтән.

2.7. Өлешләп төзүдә катнашучылар түли торган акчаларның квартал саен хисаплылыкны тикшерү, төзүчеләрнең максатчан кулланылышын тикшерү өлешендә дәүләт функциясен үтәү срогы төзүче тарафыннан соратып алына торган документларны бирү өчен кирәкле срокка, әмма 10 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин;

2.8. Дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору күз алдында тотылмый.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедераларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт функцияләрен үтәү үз эченә түбәндәге административ процедураларны үтәүне ала:

- квартал саен күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисапны тикшерү;

- 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрне үтәүне тикшерү;

- күп фатирлы йортларны төзү өчен кооператив әгъзаларының чараларын җәлеп итү белән бәйле булган торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә дәүләт контролен тормышка ашыру;

төзүчеләр тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга куелган таләпләрне тикшерү;

төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән талапләргә туры килүе турында бәяләмә бирү, яки әлеге бәяләмә бирүдән дәлилләр белән баш тарту.

3.2. Дәүләт функцияләрен үтәү блок-схемасы Административ регламентка 1 нче кушымтасында китерелгән.

3.3. Квартал саен күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисапны анализлау.

3.3.1. Административ процедураларны үтәү өчен җирлек булып, 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, төзүче белән өлешле төзелешнең беренче катнашучы белән, килешү төзүе тора.

3.3.2. Административ процедураларны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып, өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгечләре саналалар.

3.3.3. Квартал саен күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисапны кабул итү административ процедурасы төзүче тарафыннан өлешле төзелеш өлкәсендә башкарма комитет белгеченә Административ регламенттагы 2 кушымтадагы форма нигезендә тәкъдим итүдән башлана. Хисапка аңлатмалары белән белешмәләр, шулай ук төзүченең Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән, бухгалтерлык (финанс) хисапнамәсен (IV квартал нәтиҗәләре буенча - еллык) кертеләләр.

Төзүчеләрнең квартал хисаплылыгын тапшыру тәртибе төзүчеләр тарафыннан

өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында квартал саен хисап бирү кагыйдәләре белән билгеләнгән, ул Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.10.2005 ел, № 645 карары белән расланган.

Квартал саен бирелә торган хисап төзүче тарафыннан башкарма комитетка, хисап кварталы тамамланганнан соң, 30 көннән дә артмаган срокта тәкъдим итә, искәрмә буларак, төзүче тарафыннан Башкарма комитетка IV квартал тамамланганнан соң 90 көннән дә соңга калмыйча бирелә торган IV кварталдан кала.

Хисапны анализлау – бу Россия Федерациясе законнарын ачык кагыйдә бозуларның булу-булмавын, ягъни ачыклар өчен өстәмә документлар һәм мәгълүмат кирәк булмаган кагыйдә бозуларны билгеләү, хисапта күрсәтелгәннәрдән кала, яки төзүчеләрнең хисапларын карау өчен вәкаләтле булган зат – өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгече хисапны карау вакытында булганнардан кала.

Төзүченең квартал саен хисабы түбәндәге критерийлар буенча тормышка ашырыла:

1) квартал саен хисапның составы, формалары һәм бирү тәртибе Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе бәяләнә;

2) квартал саен хисаптагы мәгълүматларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе бәяләнә.

Квартал саен хисапта тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеге күп фатирлы йортлар һәм (яки) күчемсез милек объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын үтәүне планнан тыш тикшерү уздыру процессында тикшерелә.

3.3.4. Административ процедураларны үтәү срогы максималь срогы хисап кергән көннән башлап, 30 эш көнен тәшкил итә.

3.3.5. Өлешле төзү объектын өлешле төзү катнашучысына вакытында тапшырмаган һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6,8 статьялары таләпләрен үтәмәү ачыкланса, финанс тотрыклылык нормативларына туры килмәвен ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында төзүчегә күрсәтмә җибәрә.

3.3.6. Төзүченең хисабына анализ уздырган вакытта, өлешле төзү өлкәсендә административ җаваплылык каралган закон таләпләрен бозу билгеләре ачыкланган очракта, өлешле төзелеш өлкәсенә Башкарма комитет белгече, Башкарма комитет җитәкчесенең (җитәкче урынбасары) тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре нигезендә, хисапны тәкъдим иткән төзүчегә карата планнан тыш тикшерү уздыру турында Башкарма комитет җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) карар проектын әзерли. Планнан тыш тикшерүнең акты һәм материаллары, шулай ук күрсәтмәне үтәмәү буенча мәгълүмат хокук саклау органнарына җибәрелә.

3.3.7. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2.3 бүлегендә күрсәтелгән фактлар ачыкланса, күчемсез милеккә карата һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларга дәүләт теркәвен тормышка ашыручы орган, билгеле карар кабул ителгәннән соң 1 (бер) эш көненнән артмаган чорда, башкарма комитет тарафыннан төзүчедә гражданнар - күп фатирлы йортлар төзү (булдыру) өлешле төзелеш катнашучылар акчаларын төзелешкә җәлеп итү турында хокук булмавы турында, 14-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2.3 бүлегендә күрсәтелгән карарларны да беркетеп, хәбәрнамә җибәрелә.

3.3.8. Төзүче хисабының төп нөсхәләре Башкарма комитетта саклана. Аларны

бирү бары тик хокук саклау һәм суд органнары соратулары буенча гына каралган.

3.3.9. Башкарма комитет җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) күрсәтмәләре нигезендә, төзүчеләрнең квартал саен хисабын анализлау процессына кертелгән мәсьәләләр, төзүчеләрне тикшерүне планлаштырганда һәм уздырганда кулланыла.

3.3.10. Башкарма комитет тарафыннан административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып Юридик затны тикшерү акты тора (административ регламентка 4 кушымта) (тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланды).

3.4. Төзүче һәм өлешләп төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затларның 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәвен тикшерү;

3.4.1. Тикшерүнең предметы булып тора:

өлешле төзелештә катнашучылар түли торган акчаларны төзүчеләр тарафыннан максатчан файдалануны контрольдә тоту;

214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүне тикшерү;

3.4.2. Административ процедура планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә, документар һәм күчмә формада, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьялары белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

Төзелеш эшләре алып барыла торган Биектау муниципаль районы территориясендә контрольлек итүче орган тарафыннан планлы тикшерү үткәрү өчен, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка, төзелешкә рөхсәт биргән көннән яисә төзелеш алып барыла торган Биектау муниципаль районы территориясендә мондый затның соңгы планлы тикшерүен үткәрү датасыннан бер ел үтү нигез булып тора.

План Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында”, 2010 ел, 30 июнь, 489 номерлы карары таләпләре нигезендә эшләнә.

Планлы тикшерүләр уздыру елына кадәрге агымдагы елның 1 сентябренә кадәр, планлы тикшерүләр уздыруның план проекты Биектау районы прокуратурасына (алга таба - прокуратура) җибәрелә.

Прокуратураның кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен алганнан соң һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча, планлы тикшерүләр уздыру елына кадәрге елның 1 ноябренә кадәр, планлы тикшерүләр уздыруның расланган еллык планы прокуратурага җибәрелә. План Башкарма комитет органы җитәкчесе урынбасары тарафыннан килештерелә һәм башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана.

Башкарма комитет планлы тикшерү уздыру турында юридик затка ул уздырылганчыга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, башкарма комитет җитәкчесенең, җитәкчесе урынбасарының планлы тикшерү уздыру башлануы турында әмернамә (боерык) күчермәсен кулга тапшыру тамгасы белән почта аша

заказлы хат итеп җибәреп һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр дә мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булса яисә элегрәк юридик зат тарафыннан башкарма комитетка тапшырылган булса, юридик затның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә яисә башка төрле ысул белән хәбәр итә.

Боерыкны Башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) имзалый.

3.4.3. Башкарма комитет тарафыннан, планнан тыш тикшерү рәвешендә административ процедура уздыру өчен җирлек булып тора:

1) күпфатирлы йортлар төзү һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектлары төзелеше өчен гражданнардан акчалар җәлеп итүче юридик зат тарафыннан, элек бирелгән 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозуны бетерү турында күрсәтмәнең, шулай ук Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый документлары, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән, күп фатирлы йортлар төзү һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектлары төзелеше өчен гражданнардан акчалар җәлеп итү мәсьәләләре буенча башка таләпләрнең башкару срогы чыгу, әгәр дә әлеге срок чыкканчыга кадәр күп фатирлы йортлар төзү һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектлары төзелеше өчен гражданнардан акчалар җәлеп итүче зат тарафыннан күрсәтмәдә күрсәтелгән кагыйдә бозулар бетерелмәгән булсалар;

1.1) Башкарма комитетка юридик заттан хокукый статус, аерым эшчәнлек төрләрен тормышка ашыру өчен хокук бирә торган махсус рөхсәт (лицензия) яки башка юридик мөһим гамәлләр башкару өчен рөхсәт (килешү) бирү турында гариза килү, әгәр дә юридик затны билгеле планнан тыш тикшерү уздыру, хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия), рөхсәт (килешү) бирү кагыйдәләре белән каралган булса;

2) башкарма комитетның вазыйфаи затының юридик зат белән мөнәсәбәтләргә кермичә тикшерү уздыру буенча анализлау нәтиҗәләре буенча чараларның нәтиҗәләрен дәлилләп тәкъдим итү, башкарма комитетка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән түбәндәге фактлар турында мәгълүматларны карау яки алдан тикшерү:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, уникаль документларына, милли китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документлар өчен зыян килү куркынычы, дәүләтнең иминлеге, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү мөмкинлеге;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының

аеруча кыйммәтле, уникаль документларына, милли китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документлар өчен зыян килү, дәүләтнең иминлеге, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

2.1) юридик зат белән мөнәсәбәтләргә кермичә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча чаралар уздырганда «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.1 статьясы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән, юридик затларның эшчәнлек параметрларының туры килүен яки тайпылышларын ачыклау, башкарма комитет белән расланган риск индикаторлары буенча, федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре турында нигезләмәдә каралаган, планнан тыш тикшерү уздыру буенча нигез булып тора;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча, законнар үтәлешен тикшерү кысаларында планнан тыш тикшерү уздыру турында прокурор таләбе буенча чыгарылган башкарма хакимият җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) боерыгы;

4) төзүченең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелеш катнашучыларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен квартал саен хисабына һәм проект декларациясенә анализ уздырганда, күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелеш катнашу турында законнар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыклану;

5) Башкарма комитетка 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның, Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актлары, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актларының мәҗбүри таләпләрен бозу очраклары турында гражданнардан, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәреннән мәгълүматлар килү;

5.1) төзүченең проектны тормышка ашыру якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк айга тайпылуы;

Административ регламентның 3.4.3 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан уздырганда «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы 12 өл. белән билгеләнгән тәртиптә, прокуратура органнарына хәбәр итеп кичекмәстән уздырыла ала. Өлешле төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче юридик затка андый тикшерү уздырылуы турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында, юридик затка планнан тыш тикшерү уздыру башлану турында аның башлануына кадәр 24 сәгать кала (егерме дүрт) теләсә нинди мөмкин булган ысул белән карар күчермәсен җибәрү юлы

белән, шул исәптән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр дә мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булса яисә элегрәк юридик зат тарафыннан Башкарма комитетка тапшырылган булса, юридик затның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә яисә башка төрле ысул белән хәбәр ителә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуларны җибәргән зат турында дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат булмаган очракта, мәҗбүри таләпләрне бозучы булып, мәҗбүри таләпләрне бозу турында җитәрлек мәгълүматлар, Башкарма комитет тарафыннан килгән мәгълүматны алдан тикшерү уздырылырга мөмкин. Алдан тикшерү уздыру барышында гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр җибәргән мәгълүмат тәкъдим иткән затлардан, өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар сорату буенча чаралар күрелә, Башкарма комитет карамагында булган юридик затның документларын карау уздырыла. Кирәк булган очракта юридик зат белән мөнәсәбәтләргә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматларны тәкъдим итү турында йөкләмәләр һәм башкарма комитет таләпләрен үтәүне йөкләмичә, тормышка ашырыла торган контроль буенча чаралар уздырыла. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан алынган мәгълүматлар буенча аңлатма язулары соралырга мөмкин, ләкин андый аңлатмаларны һәм башка документларны бирү мәҗбүри булып саналмый.

3.4.4. Административ процедураны тормышка ашыру буенча җаваплы затлар булып, өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгечләре санала.

3.4.5. Төзүче тарафыннан тикшерү өчен тәкъдим ителә торган документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 ел, 11 октябрь, 750 номерлы карарында күрсәтелгән.

3.4.6. Административ процедураны үтәүнең максималь срогы – 20 эш көне.

3.4.7. Административ процедураны башкару төзүче тарафыннан административ процедураны тормышка ашыру өчен кирәкле документларны бирмәгән очракта туктатып тору мөмкин түгел һәм РФ КоАП 14.28 статьясы 4 өлеше буенча административ кагыйдә бозулар турында эш кузгатуны күз алдында тота.

3.4.8. Башкарма комитет тарафыннан административ процедураны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып юридик затны тикшерү Акты санала (Административ регламентка 4 кушымта) (Тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланды).

Актта тикшерү нәтиҗәләре һәм ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү өчен кабул итәргә кирәкле (кабул ителгән) чаралар күрсәтелә.

Тикшерү акты турыдан-туры планнан тыш тикшерү узганнан соң ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуның берсе, кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка тапшырыла. Җитәкче, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышу турында распика яисә

танышудан баш тарту очрагында акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, ул Башкарма комитет эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда хәбәрләмә һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының Башкарма комитетта саклана торган эштәге нөсхәсенә кушып куела.

Планнан тыш тикшерүне уздыру өчен аны уздыру өчен прокуратура органнары белән килештерү таләп ителгән очракта, тикшерү акты күчермәсе, тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул ителгән прокуратура органына, тикшерү акты төзелгән көннән башлап, биш эш көне эчендә җибәрелә.

3.4.9. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан уздырылган тикшерү буенча административ процедуралар башкару нәтиҗәләре буенча юридик затларны тикшерү Журналында язып куела (тикшерүне исәпкә алу журналының типик формасы Россия икътисади үсеш министрлыгының 2009 ел, 30 апрель, 141 номерлы боерыгы белән расланган). Тикшерүне исәпкә алу журналы булмаган очракта, тикшерү актында тиешле язма языла. Тикшерү акты нөсхәсе башкарма комитетта саклана, аларны бирү хокук саклау һәм суд органнары соратулары буенча гына бирелә.

3.5. Күп фатирлы йортлар төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен тормышка ашыру.

3.5.1. Административ процедураны үти башлауга нигез булып торак-төзелеш кооперативын дәүләт теркәвен тормышка ашыру тора.

3.5.2. Күп фатирлы йортлар төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген тикшерү предметы булып тора:

Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясы 3 өл. таләпләрен үтәү,

алга таба күпфатирлы йортны тотудан кала;

Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясының торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген үтәү өлешендә;

Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 статьясы 1 пункты белән билгеләнгән торак кооперативы вазыйфаи затларына таләпләргә туры килүе.

3.5.3. Админстратив процедура планлы һәм планнан тыш тикшерүләр формасында документар һәм (яки) урынга чыгу формасында «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 2 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьялары белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3.5.4. Административ процедураны тормышка ашыру буенча җаваплы затлар булып, өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгечләре санала.

3.5.5. Контрольне тормышка ашырган вакытта башкарма комитетның вазыйфаи затлары хокуклы:

1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә рәсми статистик мәгълүматны формалаштыру буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан һәм аның территориаль органнарыннан, күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

2) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы 1 өл. белән билгеләнгән алар тарафыннан мәгълүматлар һәм документлар урнаштыруга таләпләрне тотуга контрольне тормышка ашырырга;

3) җирле үзидарә органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә (шул исәптән күпфатирлы йорт (яисә) күчемсез милекнең башка объектын төзүгә бәйле документларны), торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны (шул исәптән күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле документларны) һәм мәгълүматларны җирле үзидарә органнарыннан алырга;

4) Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (андагы белешмәләрне), торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йорт төзелеше өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

5) Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 статьясының 1 пунктында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

6) дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

тәртибендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йорт төзелеше өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алу;

7) торак-төзелеш кооперативыннан һәм күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле шартнамәләр төзегән бүтән затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы белән билгеләнгән чорда, исемлеге Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары белән билгеләнән торган, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йорт төзелеше өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

8) квартал саен төзүчедән, торак-төзелеш кооперативыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруы турында, шул исәптән, мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар каршында үз бурычларын үтәве турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптәге рәвешләр буенча аралык һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисапнамәсен, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән аралык һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алырга;

9) Регламентрың 3.6.2. пунктлары нигезендә, күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчасын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген тикшерү;

10) торак-төзелеш кооперативы идарәсеннән ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерүне таләп итү;

11) торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясы 3 өл. таләпләрен бозу белән бәйле, гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләрен карау, алга таба күп фатирлы йортны карап тоту һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясыннан кала;

12) күпфатирлы йорт төзелешендә үз акчасы белән катнашучы торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап гариза белән судка мөрәҗәгать итү, мондый хокуклар һәм мәнфәгатьләр бозылган очракта;

13) торак-төзелеш кооперативына Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясы 3 өл. таләпләрен бозуны бетерү мәҗбүри булган күрсәтмәне үтәү турында җибәрү, алга таба күп фатирлы йортны карап тоту һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясыннан кала һәм әлеге кагыйдә бозуларны бетерүнең срокларын билгеләү;

14) әлеге статья һәм административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән, торак-төзелеш кооперативы, аның вазыйфаи затларын җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрергә;

15) хокук саклау органнарына мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле, җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре ачу турында мәсьәләләрне хәл итү өчен материалларны җибәрергә;

16) Федераль законнар белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3.5.6. Административн процедура уздыру вакытында тикшерелә:

1) торак-төзелеш кооперативы әгъзалары саны;

төзелешендә торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үзләренең шәхси акчасы белән катнаша торган күпфатирлы йорт төзелешенә рөхсәт;

күпфатирлы йорт төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлегенә торак-төзелеш кооперативының хокуклары, шул исәптән җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документ реквизитлары, җир кишәрлегенең милекчесе турында белешмәләр (торак-төзелеш кооперативы җир кишәрлегенең милекчесе булып тормаган очракта), төзекләндерү элементлары турында белешмәләр;

төзелә торган күпфатирлы йортның урнашкан урыны һәм аның төзелешкә рөхсәт бирүгә нигез булган проект документациясе нигезендә әзерләнгән тасвирламасы;

төзелә торган күпфатирлы йортта торак урыннар саны, проект документациясе нигезендә мондый торак урыннарына техник сыйфатламаларны тасвирлау, шулай ук проект документациясенә тиешле үзгәрешләр кертелгән очракта күрсәтелгән мәгълүматларны үзгәртү;

төзелә торган күпфатирлы йортны эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт алуның күздә тотылган срогы;

кооператив уставы;

кооператив әгъзалары реестры.

2) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы 3 өл. таләпләр нигезендә кооператив әгъзалары реестрын алып бару.

3) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы 2 һәм 4 өл. таләпләрен үтәү.

4) Бер үк вакытта бердән дә артмаган катлар саны өчтән дә күп булмаган күп фатирлы йортны төзүне тормышка ашыру буенча таләпләрне тоту.

Торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрында булган мәгълүматлар, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы белән каралган башка мәгълүматларны вазыйфаи затлар торак-төзелеш кооперативлары дәүләт мәгълүмати системасыннан ала алалар.

3.5.7. Планлы тикшерү уздыру өчен җирлек булып торак-төзелеш кооперативына төзелеш өчен рөхсәт бирү датасыннан яисә төзелеш тормышка ашырыла торган Россия Федерациясе субъекты территориясендә әлеге кооперативны ахыргы планлы тикшерү уздырган датадан 1 ел узуы тора.

3.5.8. Торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып тора:

1) торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортлар һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативының 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлануы, шулай ук күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка таләпләр, әгәр мондый вакыт чыкканчы, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның

акчаларын җәлеп итүче зат күрсәтмәдә күрсәтелгән бозулар бетерелмәсә;

2) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү (төзү) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында төзүченең квартал саен хисаплылыгын, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтер хисаплылыгын (шул исәптән еллык) һәм (яки) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыклау;

3) контрольлек итүче органга гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.4 ст. 1 өл. күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле орган, җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары таләпләрен бозу фактлары турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү;

4) төзүчене төзелеш проектын гамәлгә ашыруның якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк вакытка тайпылу;

5) Башкарма комитет җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы күрсәтмәләре нигезендә, әлеге 214-ФЗ номерлы Федераль законның һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары мәҗбүри таләпләрен бозу очрагында чыгарылган күрсәтмәсе;

6) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе;

5) Башкарма комитетка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.4 ст. 1 өл. күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле орган, җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары таләпләрен бозу фактлары турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү;

5.1) торак-төзелеш кооперативы төзелеш проектын гамәлгә ашыруның якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк вакытка читләштерү;

Административ регламентның 3.5.8 пункты 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча урынга чыгып планнан тыш тикшерү башкарма комитет тарафыннан прокуратура органнарын «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы 12 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә, хәбәргә куеп

кичекмәстән уздырыла ала. Өлешле төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче юридик затка андый тикшерү уздырылуы турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

3.5.9. Планлы һәм планнан тыш төрдә административ процедураны уздыру тәртибе административ регламентның 3.4 пункты белән билгеләнгән.

3.5.10. Башкарма комитет тарафыннан административ процедураны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тикшерү Акты санала (административ регламентка 4 кушымта) (Тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланды).

Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күрсәтмәдә билгеләгән чорда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, шулай ук мондый бозулар торак-төзелеш кооператив әгзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә чын куркыныч тудырганда, башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан, торак-төзелеш кооперативы тиешле бозуларны бетергәнчегә кадәр кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктатып тору турында күрсәтмә чыгарырга хокуклы. Аның күрсәтмәләре торак-төзелеш кооператив тарафыннан үтәлмәгән очракта бу кооперативны ликвидацияләү турында таләп итеп судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6. Төзүчеләр тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга куелган таләпләрне тикшерү;

3.6.1. Административ процедураларны үтәүне башлау өчен җирлек булып Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән өлешле төзелештә катнашу беренче килешүен теркәү тора.

3.6.2. Административ процедураны тормышка ашыру буенча җаваплы затлар булып, өлешле төзелеш өлкәсендә башкарма комитет белгечләре санала.

3.6.3. Административ процедура уздыру бердәм торак төзелеше мәгълүмати системасында төзүче тарафыннан үз эшчәнлеге турында "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында мәгълүмат урнаштыруны тикшерү тора.

3.6.4. Тикшерелергә тиешле оешмалар исемлеге, башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана торган еллык план нигезендә билгеләнә. Планга кертү өчен җирлек булып төзүчегә төзелешкә рөхсәт бирү датасыннан, яисә проект декларациясен ахыргы планлы тикшерү уздыру тәмамланган датадан бер ел узып китү тора.

Төзүчеләр тарафыннан мәгълүматларны (проект декларациясен) ачу һәм урнаштыруга билгеләнгән таләпләрне планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып, Башкарма комитетка гражданнардан, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүматлар килү тора.

3.6.5. Тикшерү предметы булып, төзүче тарафыннан түбәндәге мәгълүматны урнаштыру тәртибе һәм сроклары тора:

1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы 1 өлеше 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт;

2) төзүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегенең гамәлгә ашырылуы турында соңгы ел өчен аудитор бәяләмәсе (әгәр дә төзелеш өчен рөхсәт 2018 елның 1 нче

июленә кадәр алынган булса);

3) төзелешкә рөхсәт;

4) проект документациясенә экспертиза бәяләмәсе, әгәр мондый экспертизаның үткәрелүе Россия Федерациясе законнары белщн билгеләнгән булса;

5) төзүченең җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар;

6) проект декларациясе;

7) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында Башкарма комитет бәяләмәсе;

8) өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе проекты яисә төзүче тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү өчен кулланыла торган, 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән кагыйдәләргә җавап бирә торган мондый шартнамәләрнең проектлары;

9) төзүче тарафыннан компенсация фондына мәҗбүри күчерүләрне (кертемнәрне) түләү турында мәгълүматлар (әгәр дә беренче өлешле төзелеш катнашучысы белән өлешле төзелеш шартнамәсендә катнашу дәүләт теркәвенә “Гражданнар – өлешле төзелештә катнашучыларның хокукларын яклау фонды” дәүләт теркәвен узган датадан соң тәкъдим ителгән булса) яки 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьялары таләпләре нигезендә, өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү шартлары, урнаштырылган очракта;

10) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясы 2 өл. нигезендә, өлешле төзелештә катнашу килешүе буенча вазыйфалар үтәлешен тәэмин итүнең төзүче тарафыннан сайланган ысуллары (әгәр дә төзелеш өчен рөхсәт 2018 елның 1 нче июленә кадәр алынган булса);

11) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясы 3 бүлегендә каралган очракта 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.3 статьясы нигезендә төзүче белән төзелгән җаваплылык алу (поручительство) килешүе (әгәр дә төзелеш өчен рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган булса);

12) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3статьясы 5 бүлегендә күрсәтелгән документлар (әгәр дә төзелеш өчен рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган булса);

13) төзүче тарафыннан күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты өлешле төзелешендә катнашучылар акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган, аларның хәзерге вакытта төзелеш (булдыру) халәтләрен күрсәтә торган фотографияләр;

20) 214-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган башка мәгълүмат.

3.6.6. Проект декларациясен тикшерү вакытында билгеләнәләр:

проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 20, 21 статьялары таләпләренә туры килүе;

күздә тотылган үзгәрешләрне кертү тәртибен һәм срокларын тоту.

Өлешле төзелеш катнашучылар акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган һәрбер күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка төр күчемсез милек объектын бердәм торак төзелеше мәгълүмат системасында урнаштыру тәртибенә таләпләр Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

тарафыннан билгеләнә.

3.6.7. Регламентның 3.6.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясында күрсәтелгән торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында, башкарма комитеттан төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл., 20 һәм 21 статьяларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә алганнан соң, 5 эш көне дәвамында урнаштырылырга тиеш. Административ регламентның 3.6.5 пункты 13 пунктчасында күрсәтелгән фотосурәтләр күрсәтелгән системада ай саен урнаштырылырга тиешле.

3.6.8. Административ регламентның 3.6.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар һәм документларга кертелгән үзгәрешләр, төзүченең рәсми майтында әлеге үзгәрешләр кертелгән көннән 5 (биш) эш көне дәвамында кертелергә тиешле.

3.6.9. Административ процедураны үтәүнең максималь срогы 3 (өч) эш көнен тәшкил итә.

3.6.10. Административ процедураны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тикшерү Акты санала (административ регламентка 4 кушымта) (Тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланды).

3.6.11. Административ җаваплылык каралган закон бозулар ачыкланган очракта, тикшерү акты прокуратурага бирелә.

3.7. Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл., 20 һәм 21 статьяларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү (алга таба - бәяләмә);

3.7.1. Административ процедераны үтәүне башлау өчен нигез булып, төзүченең проект декларациясе турында гариза дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына керүе санала.

3.7.2. Проект декларациясенең электрон формасын “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасы сайтында тутыруның техник мөмкинлеген тәэмин иткәнчегә кадәр, төзүче 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2 өл. нигезендә, проект декларациясен Россия Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 ел, 22 декабрь, 996/пр номерлы боерыгы белән расланган формада Башкарма комитетка җибәрә.

Проект декларациясе бергә теркәп җибәрелә торган хат (гариза) белән почта белән, башкарма комитетның электрон почтасына яки курьер хезмәте белән җибәрелә ала. Бергә беркетелеп җибәрелә торган хатта төзүче белән элемтәгә керү (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, хәбәрләшү өчен телефоннар һәм e-mail) һәм бәяләмә алу юллары күрсәтелә.

Төзүче проект декларациясе белән бергә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл. 1, 7 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән документларны бирергә хокуклы.

Төзүче проект декларациясе белән бергә башкарма комитетка Административ регламентның 5 кушымтасында күрсәтелгән исемлек буенча документларны тәкъдим итә.

3.7.3. Администртив регламентның 3.7.2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, электрон документлар әйләнеше системасында теркәләләр һәм

башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) белгечләре үтәлешенә җибәреләләр.

3.7.4. Административ процедураны тормышка ашыру буенча җаваплы вазыйфаи затлар булып, өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгечләре санала.

3.7.5. Административ процедураны тормышка ашырган вакытта 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл., 20 һәм 21 статьяларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү тора.

3.7.6. Бәяләмә проектын әзерләү өчен җаваплы булган белгеч, 5 календарь көн дәвамында тиешле соратуларны җибәрә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә:

Россия Федераль салым хезмәтенә – төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл., 7, 8 статьяларында күрсәтелгән таләпләрне үтәвен контрольдә тотуны тормышка ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар алу өчен;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына - төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл., 8 статьяларында күрсәтелгән таләпләрне үтәвен контрольдә тотуны тормышка ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар алу өчен;

3.7.7. Бәяләмә проектын әзерләү өчен җаваплы булган белгеч, 10 календарь көн эчендә төзүче – юридик зат турында мәгълүмат ала:

egrul.nalog.ru - Россия Федераль салым хезмәте сайтында – бетерү процедурасы булуы (булмавы) турында;

kad.arbitr.ru - Россия Федерациясе Арбитраж суды сайтында административ җәза чарасы сыйфатында аның эшчәнлеген туктату турында, бөлгенлеккә төшү турында процедураларның берсен кертү турында карар булуы (булмавы) турында;

old.zakupki.gov.ru – сатып алулар өлкәсендә Бердәм мәгълүмат системасы сайтында – “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында”, 2011 ел, 18 нче июль, 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган эшенә игътибарсыз караучы тәэмин итүчеләр реестрында мәгълүматның булуы (булмавы);

rnp.fas.gov.ru – Россия Монополиягә каршы федераль хезмәте сайтында - “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 ел, 5 апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган, эшенә игътибарсыз караучы тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында мәгълүматның булуы (булмавы);

torgi.gov.ru – сатулар уздыру турында мәгълүматны урнаштыру өчен Россия Федерациясе сайтында – җир кишәрлеген сату буенча, яисә җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе төзү хокукына аукцион уздыру буенча аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүматның булуы (булмавы).

Өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгече Административ регламентның 3.7.6 һәм 3.7.7 пукнтларында күрсәтелгән документларны алганнан соң:

башкарма хакимият органнарыннан алган документларны карау һәм

анализлауны тормышка ашыра, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында;

гомуми кулланылышта булган сайтларны куллану нәтиҗәсендә алынган документларны (мәгълүматны) карау һәм анализлауны тормышка ашыра;

мөрәҗәгать итүченең проект декларациясендә булган мәгълүматның (РФ Төзелеш Министрлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы белән расланган форма буенча бирелгән) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү фактын билгели;

гариза бирүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 өл. күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү фактларын билгели;

электрон документ әйләнеше системасында төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьяларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында Регламентның 6 кушымтасы нигезендә, бәяләмә проектын әзерли. Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, бәяләмә бирүдән баш тарту бирү турында карар белән хат проектын әзерли.

3.7.8. Бәяләмә бирүне туктатып тору өчен нигез булып, Башкарма хакимият органнарында һәм оешмаларында, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет тарафыннан соратылган докментлар һәм мәгълүматларның булмавы һәм гариза бирүчедән өстәмә документлар сорату кирәклеге тора.

Административ регламентның 3.7.8. пункты белән каралган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигез ачыкланган очракта, өлешле төзелеш өлкәсендә башкарма комитет белгече электрон документ әйләнеше системасында бәяләмә бирүне туктатып тору турында карар белән хат проектын әзерли һәм җитәкче урынбасары на килештерүгә һәм Башкарма комитет җитәкчесенә имзалауга җибәрә.

Бәяләмә бирүне туктатып тору өчен булган сәбәпләрне бетергәннән соң, өлешле төзелеш өлкәсендә башкарма комитет белгече электрон документ әйләнеше системасында бәяләмә бирүне кабаттан булдыру турында карар белән хат проектын әзерли һәм җитәкче урынбасары на килештерүгә һәм башкарма комитет җитәкчесенә имзалауга җибәрә. Башкарма комитет җитәкчесе бәяләмә бирүне туктатып тору/кабаттан булдыру турында карар белән хат проектын алган көннән соң, икенче көннән дә соңга калмыйча аны имзалый. Имзаланган документлар хатны теркәү өчен, хатларны теркәүне тормышка ашыручы (алга таба – гомуми бүлек белгече) Биектау муниципаль районы белгеченә җибәреләә.

Гомуми бүлек белгече гариза бирүчегә, билгеләнгән тәртиптә башкарма комитет җитәкчесе белән имзаланган бәяләмә бирүне туктатып тору/кабаттан булдыру турында карар белән хат проектын, хат имзаланганнан соң, икенче көннән дә соңга калмыйча, җибәрүне тәэмин итә.

Билгеле бәяләмәне бирүдә төзүченең һәм (яки) проект декларациясенең билгеләнгән тәртипләргә туры килмәве ачыкланган очракта кире кагыла. Башка төр нигезләр буенча бәяләмәне бирүдән баш тарту рөхсәт ителми.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган бәяләмә яки теркәлүгә җибәрелгән дәлилләнгән кире кагу.

Өлешле төзелеш өлкәсендә Башкарма комитет белгече:

гомуми бүлек белгеченнән теркәлгән бәяләмәне ала (бәяләмә бирүдә кире кагу

туырнда);

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) беркетелгән хатта күрсәтелгән элемтә ысулы белән, бәяләмә бирү нәтиҗәләре турында, рәсмиләштерелгән бәяләмәне бирү яки бәяләмә бирүдән кире кагу турында хатны бирү датасы һәм вакыты турында хәбәр бирә;

Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән бәяләмәне алу турында тамга куйдырып яки кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, бәяләмә бирүне кире кагу турында хат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнән торган процедуралар, гариза бирүче килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмә бирү турында бирелгән бәяләмә яки кире кагу турында зат.

3.7.9. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән сорату килгән очракта бәяләмә (дәлилләнгән кире кагу) сорату алынган көннән башлап, ике эш көненнән дә артмаган вакытта тәкъдим ителә.

## IV. Дәүләт функциясенең үтәлүен контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Башкарма комитет вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт функциясен үтәүгә таләпләрне билгеләүче Регламент нигезләмәләре һәм хокукый актларны үтәү һәм тоту буенча агымдагы контроль, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итү Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе һәм алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тормышка ашырыла.

4.2. Дәүләт функциясен үтәүгә карата агымлагы контроль, башкарма комитетның вазыйфаи затлары кабул итә торган карарлар һәм гамәлләрне планлы һәм планнан тыш тикшерү юлы белән тормышка ашырыла.

4.3. Контроль нәтиҗәләре буенча гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, шулай ук вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү тәртибе

5.1. Башкарма комитет вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәгән вакытта кабул ителгән карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаятьне язма формада яки электрон документ формасында җибәрү юлы белән, шулай ук телдән (шәхси кабул итү вакытында) шикаять ителергә мөмкин.

Гариза бирүче язмача формада җибәрелгән үз шикаятендә, мәҗбүри рәвештә язмача мөрәҗәгать җибәрелә торган дәүләт функциясен үтәүче органның исемен яки дәүләт функциясен үтәүче органның вазыйфаи затының фамилиясе, исемен, әтисенең исемен яки билгеле затның вазыйфасын күрсәтә, шулай ук үз фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (ахыргысы булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресын, шикаятьнең эчтәлеген яза, шәхси имзасын һәм датаны куя.

Башкарма комитетка электрон документ формасында килгән шикаять, “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”, 2006 ел, 2

нче май, 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә карала. Шикаятьтә гариза бирүче үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (ахыргысы булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Гариза бирүче әлеге шикаятькә кирәкле документлар һәм материалларны электрон формада беркетергә хокуклы.

Үз дәлилләрен расларга кирәк булган очракта, гариза бирүче шикаятькә (дәгъвага) документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләре беркетелә.

5.2. Шикаятьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданинның фамилиясе, яки җавап җибәрелергә тиешле почта (электрон) адресы күрсәтелмәгән очракта, шикаять буенча җавап бирелми.

Суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять, теркәлгән соң 7 көн дәвамында шикаятьне җибәргән гражданинга, әлеге суд карарына шикаять беледерү тәртибен аңлатып кире кайтарыла.

Әгәр дә шикаять текстын укырга мөмкин булмаса шикаятькә җавап бирелми, һәм ул аларның компетенцияләре чикләрендә, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка каралу өчен җибәрелми, бу хакта шикаять теркәлгәннән көннән башлап 7 көн дәвамында гражданинга хәбәр ителә.

5.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү процедурасын башлау өчен нигез булып гариза бирүче тарафыннан язма формада кәгазьдә, электрон формада яки шәхсән үзе мөрәҗәгать итү тора.

Шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, Биектау муниципаль районы рәсми сайты аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталын кулланып җибәрелергә, шулай ук башкарма комитет вазыйфаи затлары тарафыннан гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять карала:

башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан кабул ителгән карарларга – теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә;

административ хокук бозулар турында эшләр буенча карарга – 10 календарь көн.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турында җавап, электрон почта адресы аша башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон документ формасында электрон почта адресы аша, һәм язмача формада башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән язмачча формада почта адресы буенча җибәрелә. Моңа өстәп, башкарма комитетка кергән мөрәҗәгать ачыкланмаган затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдимнәр, гариза яки шикаятьләрне үз эченә алса, аерым алганда, ачыкланмаган затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелсә, шул исәптән, суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”, 2006 ел, 2 нче май, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы 2 бүлеге таләпләрен тотып дәүләт органы яки җирле үзидарә органының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәурнаштырылырга мөмкин.

5.6. Кызыксынган затлар, дәүләт функцияләрен үтәү барышында дәүләт функциясен үтәүче башкарма комитетның, аның хезмәткәрләренең гамәлләренә һәм гамьсезлекләренә, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә, кабул ителгән карарларга шикаять белдерергә хокуклы.

5.7. Шушы Регламентта җайга салынмый торган мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә.

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын Биектау муниципаль районы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентына 1 нче кушымта

## Күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә контрольне тормышка ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда гамәлләренең эзлеклелеге блок-схемасы




Выявление признаков административного правонарушения
Направление предписаний по устранению выявленных нарушений
соответствие застройщика и проектной декларации требованиям, установленным ч. 2 ст. 3, ст. 20 и 21 Федерального закона N 214-ФЗ
не соответствие застройщика и проектной декларации требованиям, установленным ч. 2 ст. 3, ст. 20 и 21 Федерального закона N 214-ФЗ
rnp.fas.gov.ru
torgi.gov.ru
Хранение, согласно установленным срокам
Контроль исполнения направленных предписаний.
Направление акта и материалов проверки в прокуратуру
old.zakupki.gov.ru
Заключение о соответствии застройщика и проектной декларации требованиям, установленным ч. 2 ст. 3, ст. 20 и 21 Федерального закона N 214-ФЗ
Мотивированный отказ в выдаче заключения
застройщик
УФРС по МО

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын Биектау муниципаль районы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентына 2 нче кушымта

**1нче форма**

**Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында _______________ елга төзүченең хисаплыгы (квартал, ел)**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Төзүченең тулы (фирма) атамасы (индивидуаль эшкуарлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт белешмәләре) рус телендә | |
| 2. | Төзүченең- юридик затның кыскартылган рус телендә атамасы | |
| 3. | Төзүченең урнашкан урыны(юридик адресы, яшәү урыны) | |
| 4. | Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) | |
| 5. | Төзүчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия Турында белешмәләр(лицензия номеры, бирелү датасы, лицензияне биргән орган,гамәлдә булу срогы)* | |

* Белешмәләр төзелеш эшчәнлегенең әлеге төрен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очракта, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта тапшырыла.

**2 нче форма**

**Төзүче тарафыннан өлешле төзү катнашучыларының акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектлары турында мәгълүматлар**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Күчемсез милек объектының исеме (функциональ билгеләнеше, катлар саны һәм б.ш.) | |
| 2. | Күчемсез милек объектының урнашкан урыны (төзелеш адресы) | |
| 3. | Күчемсез милек объектын төзү (булдыру)өчен бирелгән җир кишәрлегенә теркәлгән милек хокукы яки аренда хокукы турында мәгълүмат(дәүләт теркәве номеры, теркәү датасы) | |
| 4. | Төзелешкә(булдыруга)рөхсәт турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат:<br>номеры, бирү датасы, кем тарафыннан бирелде | |
| 5. | проект декларациясен бастырып чыгару яки урнаштыру турында мәгълүмат(басманың яки урнаштыруның датасы һәм урыны) | |
| 6. | Аларга карата өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре төзелергә мөмкин булган күчемсез милек объекты составында мөстәкыйль өлешләрнең гомуми саны | |
| 7. | Күчемсез милек буенча төзелгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре турында мәгълүмат:<br><br>беренче шартнамәне төзү датасы<br><br>төзелеш (булдыру)башыннан төзелгән шартнамәләрнең гомуми саны<br><br>хисап чорында төзелгән шартнамәләр саны<br><br>хисап чорында төзелгән шартнамәләр саны<br><br>шартнамәләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы(млн. сум) | |
| 8. | Күчемсез милек объектын төзүгә (булдыруга) Кредит (заем) акчалары җәлеп итү турында мәгълүмат (җәлеп ителде яки җәлеп ителмәде). Кредит (заем) акчалары җәлеп ителгән булса, җәлеп ителгән чараларның гомуми күләме күрсәтелә (млн. сум)<br><br>Шул исәптән<br><br>Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итә башлаганчы<br><br>Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итә башлагач | |
| 9. | Өлешле төзелештә катнашучыларга өлешле төзелеш объектларын тапшыруның шартнамәләрдә каралган срогы | |
| 10. | Төзелеш тарафыннан тәмамланган күчемсез Милек объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт турында мәгълүмат:<br><br>рөхсәт номеры, бирү датасы<br><br>кем тарафыннан бирелгән<br><br>Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә | |

| | |
|---|---|
| ашырган органга рөхсәт тапшыру датасы | |
| 11. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен төзүче тарафыннан үтәлүе турында мәгълүмат:<br>үтәлгән шартнамәләр саны<br>үтәлмәгән шартнамәләр саны<br>шартнамәләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең гомуми суммасы (млн. сум) | |

**3 нче форма**

**Төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның җәлеп ителгән акчаларыннан файдалану турында белешмәләр**

(млн. сум)

| | |
|---|---|
| 1. Хисап чоры башына өлешле төзелештә катнашучыларның җәлеп ителгән акчалары калдыгы | |
| 2. Хисап чорында өлешле төзелештә катнашучыларның төзүче тарафыннан җәлеп ителгән акчалары күләме | |
| 3. Өлешле төзелештә катнашучыларның төзүче тарафыннан җәлеп ителгән акчаларының гомуми күләме(1 һәм 2 графалар күрсәткечләре суммасы) | |
| 4. Төзүче тарафыннан хисап чорында төзелеш материаллары сатып алу өчен кулланылган акча күләме | |
| 5. Төзүче тарафыннан хисап чорында төзелеш эшләрен һәм подрядчиклар хезмәт күрсәтүләрен түләүгә тотылган акчалар күләме | |
| 6. Шартнамәне өзү белән бәйле рәвештә төзүче тарафыннан хисап чорында өлешле төзелештә катнашучыларга кайтарылган акча күләме | |
| 7. Башка чыгымнар | |
| 8. Төзүче тарафыннан хисап чорында тотылган акчаларның гомуми күләме (4-7 графалар күрсәткечләре суммасы) | |
| 9. Өлешле төзелештә катнашучыларның җәлеп ителгән акчаларының хисап чоры ахырына калган өлеше (3 һәм 8 графалар күрсәткечләренең аермасы) | |

**4 нче форма**

**Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында**

**белешмәләр**

| Билгеләнгән күрсәткеч (норматив) исеме | Күрсәткеч аңлатмасы |
|---|---|
| 2. Йөкләмәләонең тәэмин ителеш нормативы $(H^{1})$* | |
| 3. Акчаларны максатчан куллану нормативы $(H^{2})$* | |
| 4. Зыянсызлык нормативы $(H^{3})$* | |

* "Күпфатирлы йортларны һәм Күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында"Федераль законның 23 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә билгеләнә торган мәгънәләр күрсәтелә.

Хисаплылык составына 1-4 нче кушымталар нигезендә хисаплар, "Өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисап тотуы турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 27 октябрендәге 645 номерлы карары белән расланган өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында квартал саен төзүчеләр тарафыннан хисап бирү Кагыйдәләре белән билгеләнгән очракларда бирелә торган белешмәләр, шулай ук төзүченең Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп төзелгән квартал саен (IV квартал йомгаклары буенча - еллык) бухгалтерлык хисабы кертелә.

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын Биектау муниципаль районы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентына 3 нче кушымта

______________________________________________________________________________________
(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы яки муниципаль контроль органы исеме)

Юридик зат, индивидуаль эшкуарны

**дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы яки муниципаль контроль органының**

**_______________________________________________ тикшерү үткәрү турында**

(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)

**_______ елның "__"__________ _____ номерлы**

**КҮРСӘТМӘСЕ (БОЕРЫГЫ)**

1. ____________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________ карата тикшерү үткәрергә.
(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
(ахыргысы – булган очракта)

2. Урнашкан урыны: _______________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(юридик затның (филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре), шәхси эшмәкәр тарафыннан факттагы эшчәнлекне тормышка ашыру һәм (яки) аның тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектларының урыннары)

3. Тикшерү уздыруга вәкил (вәкилләр) итеп затны (ларны) билгеләргә: ____________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(тикшерү уздыру өчен вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (ахыргысы – булган очракта) вазыйфасы)

4. Тикшерү уздыруга экспертлар сыйфатында эксперт оешмаларының түбәндәге вәкилләрен җәлеп итәргә: _____________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертларның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (ахырыгысы – булган очракта), вазыйфасы һәм (яки) аккредитация турында шәһадәтнамә реквизитларын күрсәтеп эксперт оешмасының исеме һәм аккредитация турында шәһадәтнамә биргән аккредитация буенча органның исеме)

5. Әлеге тикшерү түбәндәге кысаларда үткәрелә __________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төре (төрләре) исеме, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмати системасында реестр(лар), номеры(лары), функциясе(ләре)

6. Әлеге тикшерү түбәндәге максат белән уздырыла, дип билгеләргә:
______________________________________________________________________________________
